ПРОЕКТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 елның «___» апреленнән № ____

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, элек бирелгән рөхсәтләрне юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2025 елның 24 ноябрендәге 251 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, элек бирелгән рөхсәтләрне юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2025 елның 24 ноябрендәге 251 номерлы карарына тәбәндәге өстәмәләрне кертергә:

1.1. Реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, элек бирелгән рөхсәтләрне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге эчтәлектәге V бүлек өстәргә:

«V. Алдан (проактив) режимда муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру.

Муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен нигез булып торган вакыйгалар барлыкка килгәндә, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган түбәндәгеләргә хокуклы:

1) муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен әзерләүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрергә, шул исәптән ведомствоара сораулар җибәрергә, аларга җаваплар алырга, шуннан соң мөрәҗәгать итүчегә мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен кичекмәстән алу өчен тиешле хезмәт күрсәтү турында сорау бирү мөмкинлеге турында хәбәр итәргә;

2) мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамәсе булган очракта, мөрәҗәгать итүченең киләчәктә аңа бирү өчен нигез булырга мөмкин булган очракта, тиешле хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар уздырырга, шул исәптән ведомствоара гарызнамәләр җибәрергә, аларга җаваплар алырга, тиешле хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен формалаштырырга, шулай ук аны мөрәҗәгать итүчегә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып күрсәтергә һәм башкарылган чаралар турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми

порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов